# КАРАР

## Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Шәтке авыл җирлегенең Югары Мирәтәк торак пунктының гражданнар җыены буенча

**2019 елның 7 декабре** **Югары Мирәтәк авылы**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, «Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Шәтке авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, 2019 елның 7 декабрендә Югары Мирәтәк торак пунктында узган гражданнар җыенының тавыш бирү нәтиҗәләре белән хисап комиссиясе беркетмәсе төзелде, «Сез ризамы, Теләче муниципаль районы Шәтке авыл җирлегенең Югары Мирәтәк торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, көндезге уку формасында белем алучы студентлардан, 1 төркем инвалидлардан, Бөек Ватан сугышы ветераннарыннан, Россия Армиясе сафларында хезмәт итүчеләрдән тыш, 2020 елда гражданнарның 500 сум күләмендә үзара салымын кертүгә һәм җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны Олы Мирәтәк авылында чираттагы эшләрне башкару буенча юнәлтергә :

- вак таш түшәлгән юлларның чокырларын ремонтлау (вак таш җәю, килешү буенча эшләр өчен түләү), Пушкин, Үзәк урамнары буенча;
- юлларны кардан чистарту?»

« РИЗА» «КАРШЫ»?».

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турында хисап комиссиясе беркетмәсе нигезендә:

Җыенда катнашучыларның сайлау хокукына ия булучылары исемлегенә 22 кеше кертелгән;
җыенда катнашучыларның тавыш бирүчеләре саны 15 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучылар өчен түбәндәгеләр билгеләнде:

гражданнар җыенында катнашкан 15 кеше «Риза» позициясе өчен тавыш бирде;

«Каршы» позициясе өчен беркем дә тавыш бирмәде.

Бәян ителгәннәр нигезендә, гражданнар җыены карар итте:

1.Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Шәтке авыл җирлегенең Югары Мирәтәк торак пунктында гражданнар җыены булып узды, гражданнар җыены нәтиҗәләре – дөрес.

2.Мәсьәлә буенча карар кабул итәргә: «Сез ризамы, Теләче муниципаль районы Шәтке авыл җирлегенең Югары Мирәтәк торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, көндезге уку формасында белем алучы студентлардан, 1 төркем инвалидлардан, Бөек Ватан сугышы ветераннарыннан, Россия Армиясе сафларында хезмәт итүчеләрдән тыш, 2020 елда гражданнарның 500 сум күләмендә үзара салымын кертүгә һәм җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны Олы Мирәтәк авылында чираттагы эшләрне башкару буенча юнәлтергә :

- вак таш түшәлгән юлларның чокырларын ремонтлау (вак таш җәю, килешү буенча эшләр өчен түләү), Пушкин, Үзәк урамнары буенча;

- юлларны кардан чистарту?»-кабул ителгән.

3. Җыен нәтиҗәләре турында әлеге карарны гамәлдәге законнар нигезендә, шул исәптән Шәтке авыл җирлегенең Интернет челтәрендәге рәсми сайтында һәм мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә.

4. Әлеге карар гамәлдәге законнар нигезендә үз көченә керә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Шәтке авыл җирлеге Башлыгы: Ф. Г. Кадыйров